**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«10» декабрь 2019 ел** **№ 357**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 11 апрелендәге 56 нчы номерлы «Азнакай муниципаль районының конкурслар, аукционнар, котировкалар, тәкъдимнәр, сорау алу юлы белән сатып алуларны гамәлгә ашыру функцияләрен башкаручы Бердәм комиссия төзү турында»гы карары белән расланган Азнакай муниципаль районының муниципаль ихтыяҗлары өчен сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча Бердәм комиссиясенең эш тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (23.08.2018 №178 карар редакциясендә)

2014 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законның 39 нчы статьясы нигезендә, Азнакай шәһәр прокуратурасының 29.11.2009 елның 29 ноябрендәге 02-01-19/1519-2-2019 нчы номерлы «Ачыкланган коррупцион факторны бетерү максатында норматив хокукый актны үзгәртү турында»гы таләбен исәпкә алып, карар итә:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 11 апрелендәге 56 нчы номерлы «Азнакай муниципаль районының конкурслар, аукционнар, котировкалар, тәкъдимнәр, сорау алу юлы белән сатып алуларны гамәлгә ашыру функцияләрен башкаручы Бердәм комиссия төзү турында»гы карары белән расланган Азнакай муниципаль районының муниципаль ихтыяҗлары өчен сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча Бердәм комиссиясенең эш тәртибе турындагы нигезләмәгә (23.08.2018 №178 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.4.8. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4.8. 7.10., 7.11. пунктлар нигезендә, Бердәм комиссия эшенә экспертларны яки эксперт оешмаларын җәлеп итү турындагы мәсьәлә буенча фикер алышуга чыгара»;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 7.11 пунктны өстәргә:

«7.11. Конкурс документларына, конкурста катнашучыларны квалификация алды сайлап алу барышында гамәлгә ашырыла торган конкурсларда катнашуга

гаризалар, конкурсларда катнашучыларның өстәмә таләпләргә туры килү-килмәүне бәяләү максатында конкурслар үткәргәндә заказ бирүче экспертларны, эксперт оешмаларын җәлеп итәргә хокуклы..

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов